РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2023 елның 15 июне** **№70**

Кукмара поселогы Башкарма комитетының «Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәр тибындагы посеогы муниципаль берәмлеген су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемасын раслау турында» 2015 елның 22 апрелендәге 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемалары турында» 2013 елның 5 сентябрендәге 782 номерлы Карары нигезендә, Кукмара шәһәре Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлегенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемасын раслау турында» Кукмара поселок башкарма комитетының 2015 елның 22 апрелендәге 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

19 нчы таблицаның 2.4.1 пунктын түбәндәге эчтәлек белән тулыландырылырга:

| | | |
|---|---|---|
| 20 | Насослар һәм су күтәртү торбасын алыштырып, «Эшче тыкрыгы» скважинасын реконструкцияләү, КИПиА | 2024 ел |

| | | |
|---|---|---|
| 21 | Насослар һәм су күтәртү торбасын алыштырып, «Ворошилов» скважинасын реконструкцияләү, КИПиА | 2025 ел |
| 22 | Насослар һәм су күтәртү торбасын алыштырып, «Манзарас» скважинасын реконструкцияләү, КИПиА | 2026 ел |

2. Карарны Кукмара муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче вазыйфаларын**
**башкаручы** **Р.Р. Хәйруллин**